**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2021 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясенең 2021 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру турындагы тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Нуруллина Фидания Нургаяз кызына – сәхнәдә Гөрпинә (Т.Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре»), Айсылу (Н.Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу»), Мәрфуга (К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»), Мәстүрә (Н.Исәнбәтнең «Портфельле кияү»), Чәчәк (Н.Фәттахның «Кол Гали»), Сәҗидә (К.Тинчуринның «Казан сөлгесе»), Йолдыз (Х.Вахитның «Туй алдыннан»), Дилфүзә (Р.Батулланың «Кичер мине, әнкәй»), Мөршидә (З.Хәкимнең «Мин төш күрдем»), Люция (М.Гыйләҗевның «Баскетболист») кебек күренекле хатын-кыз образлары тудырган өчен;

2) Сафин Факил Миңнемөхәммәт улына – «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе һәм «Гөлҗиһан» повесте өчен;

3) Эйдинов Григорий Львовичка – «Нефть һәм заман», «Казан альбомы», «Татар әкиятләре дөньясы», «Казан серләре» графика серияләре һәм «Татар дөньясы» китабын бизәгән өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2021 ел, 23 апрель
№ ПУ-314